КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 сентябрь г.Казань № 849

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1294 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1294 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законны, «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан

беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына субвенцияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 16 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1 пунктта «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибендә:

исемендә «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 7 сеннән дә соңга калмыйча, хисаплылыкны үзәкләштереп җыю буенча «Барс.Web-Своды» мәгълүмат-аналитика системасыннан файдаланып, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килештереп билгеләнә торган формада электрон документ рәвешендә субвенцияләрне тоту турында хисап бирә.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 еннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Оборона министрлыгына һәм Россия Федерациясе Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе Оборона министрлыгы белән килештереп билгеләнә торган формада субвенцияләрне тоту турында хисап бирә.»;

8 пунктта «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алу буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктта «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу» сүзләрен «Территорияләрендә хәрби комиссариатларның структур бүлекчәләре булмаган җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин